ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МЕНДЕЛЕЕВСК МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
ТАТАР ЧАЛЛЫСЫ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕНЕҢ ТАТАР ЧАЛЛЫСЫ АВЫЛЫНДА
ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ

Татарстан Республикасы
Менделеевск муниципаль районы
Татар Чаллысы авыл җирлегенең Татар Чаллысы
торак пунктында 2024 елда
гражданнарның үзара салымын кертү турында

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**
06.04. 2024 ел № 3

«Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы « Татар Чаллысы авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге башлыгының 2024 елның 26 мартындагы 2023 елның 24 ноябрендәге 5 номерлы «Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы Татар Чаллысы авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге составына керүче Татар Чаллысы авылында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында", 2023 елның 24 ноябрендәге 6 номерлы " 2024 елда Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы Татар Чаллысы авыл җирлегенең Татар Чаллысы авылында гражданнарның үзара салымнарын кертү турында" гражданнар җыеннары карарларына үзгәрешләр кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләү турында карары нигезендә

**КАРАР ЧЫГАРДЫ:**

1. 2023 елның 24 ноябрендәге 5 номерлы «Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы Татар Чаллысы авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге составына керүче Татар Чаллысы авылында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында", 2023 елның 24 ноябрендәге 6 номерлы " 2024 елда Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы Татар Чаллысы авыл җирлегенең Татар Чаллысы авылында гражданнарның үзара салымнарын кертү турында" гражданнар җыеннары карарларына үзгәрешләр кертергә 1зм чарларны түбәндәгечә бәян итәргә:

«1) торак пункт территориясен төзекләндерү (кече архитектура формаларын һәм балалар спорт җиһазларын сатып алу һәм урнаштыру, «Челнинка»елгасына металл баскыч ясау өчен материал сатып алу һәм монтажлау).
2) Торак пункт чикләрендә җирле әһәмияттәге гомуми файдаланудагы автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту (җирлек юллары эчендә ремонтлау (җәйге һәм кышкы чорда юлларны карап тоту, килешү буенча эш өчен түләү).

3) Су белән тәэмин итү һәм су чыгару системаларын, су күтәрү манараларын, скважиналарны һәм су белән тәэмин итү чыганакларыннан су алуны, аны чистартуны, транспортлауны һәм халыкка су бирүне тәэмин итүче башка инженерлык корылмаларын проектлау, төзү һәм ремонтлау (Татар Чаллысы авылына 1 (бер) данә су насосы сатып алу);

4) Тышкы яктырту челтәрләрен, трансформатор һәм башка подстанцияләрне һәм алар астындагы мәйданчыкларны, бүлү пунктларын һәм электр элемтәләрен тәэмин итү һәм электр энергиясен тапшыруны гамәлгә ашыру өчен билгеләнгән башка җиһазларны ремонтлау (Татар Чаллысы торак пунктында энергия саклаучы яктырткычларны һәм урам яктырту лампаларын алыштыру буенча эшләр һәм хезмәтләр өчен түләү)?».

3. Әлеге карарны мәгълүмат стендларында урнаштыру юлы белән игълан итәргә, Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru/ һәм Менделеевск муниципаль районының рәсми сайтында. www mendsleevsk.tatarstan.ru “Татар Чаллысы авыл җирлеге” бүлегендә бастырып чыгарырга

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары Регистрына кертү өчен җибәрергә.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Татар Чаллысы авыл җирлеге башлыгы Т.П. Кузнецова.